**Республика Татарстан**
**Палата имущественных и земельных отношений Заинского муниципального района**

ул.Автозаводская, д.1 А,
г.Заинск, Республика
Татарстан 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы**

Автозавод урамы, 1 а йорт,
Зәй шәһәре Татарстан
Республикасы, 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«27» 05 2022г. №306П

**2021 елның 27 сентябрендәге 682П номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боерыгы нигезендә расланган «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы

**боерык бирә:**

1. «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 сентябрендәге 682П номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боерыгына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының җир мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы Т.Н. Кузнецовага йөкләргә.

**Палата рәисе** **Р.Р. Шәйхиев**